# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

1 статья. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11-12; 1994, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 3 статьяның 3 пунктында «аларны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый» сүзләре урынына «алар законнар нигезендә раслана.» сүзләрен язарга.

2. 6 статьядагы 3 пунктның 2 пунктчасыннан «юридик затларның дифференциацияле түләү» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. 7 статьяда:

1 пункттагы 1 пунктчада «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарыннан» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтеннән» сүзләренә алыштырырга;

2 пунктта:

1 пунктчада «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең урындагы затлары» сүзләренә алыштырырга;

4 пунктчада «Дәүләтнең янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга;

8 пунктчаны төшереп калдырырга;

9 пунктчаны 8 пунктча дип санарга.

4. 9 статьяда:

1 пунктның 3 пунктчасында «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарыннан» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтеннән» сүзләренә алыштырырга;

2 пунктның 2 пунктчасында «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтеннән» сүзләренә алыштырырга.

5. 11 статьяда:

2 пунктта «Дәүләт янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга;

3 пунктның 1 әлешендә «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга;

4 пунктта «Дәүләтнең янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга.

6. 14 статьяның 2 пунктында «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең» сүзләренә алыштырырга.

7. 17 статьяда:

2 пунктта «Дәүләт янгын күзәтүенең» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең» сүзләренә алыштырырга;

3 пунктта «Дәүләтнең янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга.

8. $19^1$ статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасының Гражданлык оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү буенча дәүләт комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» сүзләренә алыштырырга.

9. 21 статьяны төшереп калдырырга.

10. 22 статьяның 2 пунктында «Дәүләтнең янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга.

11. 23 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу законнар нигезендә административ җаваплылыкка китерә.»;

2 пунктны төшереп калдырырга;

3 пунктны 2 пункт дип санарга һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«2. Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең урындагы затлары салган штрафларны бүлү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

12. 29 статьяның 2 пунктында:

1 абзацта «Дәүләтнең янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга;

11 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкаруга һәм хезмәт күрсәтүләргә лицензияләр бирә;»;

13 пунктчада «Янгын куркынычсызлыгы» хисабына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте бүлекчәләре счетына» сүзләренә алыштырырга.

13. 30 статьяда:

2 пунктның 4 пунктчасында «гражданнарга - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр; предприятиеләрнең (берләшмәләрнең), учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына - ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр; хокукый затларга - йөз минималь хезмәт хакы күләменә кадәр» сүзләрен «гражданнарга, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына һәм юридик затларга законнар нигезендә» сүзләренә алыштырырга;

3 пунктның 3 пунктчасында «гражданнарга - өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

предприятиеләрнең (берләшмәләрнең), учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына - җиде минималь хезмәт хакы күләменә кадәр ;

юридик затларга - илле минималь хезмәт хакы күләменә кадәр» сүзләрен «гражданнарга, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына һәм юридик затларга законнар нигезендә» сүзләренә алыштырырга;

4 пунктның 2 пунктчасында «гражданнарга - ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

предприятиеләрнең (берләшмәләрнең), учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр» сүзләрен «гражданнарга, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына законнар нигезендә» сүзләренә алыштырырга.

14. 31 статьяда:

статьяның исемендә «Дәүләт янгын күзәтүенең» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең» сүзләренә алыштырырга;

1 абзацта «Дәүләт янгын күзәтүенең» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга;

2 абзацта «Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең урындагы затларына» сүзләренә алыштырырга;

4 абзацта «Дәүләт янгын күзәтүенең» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең» сүзләренә алыштырырга.

15. 32 статьяның 2 пунктында «Дәүләтнең янгын күзәтүе» сүзләрен «Янгынга каршы дәүләт хезмәте» сүзләренә алыштырырга.

16. 43 статьяда :
1 пунктта:
5-7 пунктчаларны төшереп калдырырга;
8-9 пунктчаларны 5-6 пунктчалар дип санарга;
2 пунктны төшереп калдырырга;
3-4 пунктларны 2-3 пунктлар дип санарга.

17. 44 статьяда:
1 өлешне түбәндәгечә бәян итәргә:
«Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстенлекле салым ташламалары законнар нигезендә бирелә.»;
2-5 өлешләрне төшереп калдырырга.

18. 45 статьяны төшереп калдырырга.

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерүне йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 22 феврале
№ 645